**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

2019 нл, 18 июнь №187

**“Апас шәһәр җирлегендә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар янындагы территорияләр чикләрен билгеләү турында " 14.05.2013 ел, № 15 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 27.12.2012 ел, № 1425 «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган гражданнарның күпләп җыелу урыннарын һәм югары хәвеф чыганакларының урнашу урыннарын билгеләү, шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар территорияләре чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү турында»карарына таянып, Татарстан Республикасы Апас шәһәр җирлеге Советы карар итте:

1.Апас шәһәр җирлеге Советының 2013 елның 14 маендагы 15 номерлы «Апас шәһәр җирлегендә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмалар һәм объектлар янындагы территорияләр чикләрен билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктта "Дулкын "йөзү бассейнына" сүзләрен “Ватан” спорт залына” сүзләренә алмаштырырга;

6 нчы пункт үз көчен югалткан дип танырга;

12 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

**"Апас шәһәр тибындагы поселогы»**
**муниципаль берәмлек башлыгы** **Р.Н. Заһидуллин**